**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Красновидово авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы Карары**

**2018 елның 13 декабре** **№ 100**

**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы Федераль закон, муниципаль хезмәт турындагы Татарстан Республикасы кодексы, Кама Тамагы муниципаль районы Уставы нигезендә, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. 2016 елның 20 апрелендәге “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советының 24 номерлы Карары белән расланган “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Красновидово авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә (алга таба- Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 13 маддәнең 1 өлешенең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3) шәхси яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы белән идарә итүдә яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга (сәяси партия идарәсендә катнашудан тыш); съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, бакчачылык, яшелчәчелек, дача куллланучылар кооперативлары, күчемсез милекчеләр ширкәтләре гомуми җыелышында катнашырга; күрсәтелгән коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә (сәяси партиядән тыш), муниципаль берәмлек идарә һәм ревизия комиссиясе әгъзаларында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез тапшырудан тыш (муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән

тәртиптә алынган эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле рөхсәте белән, бер үк башкарма орган буларак яисә аларның коллегиаль идарә итү органнары составына керүдән тыш) түләүсез нигездә катнашудан тыш (гамәлгә куючы (акционер), муниципаль берәмлек, муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль милектә булган оешмалар яки идарә итүне гамәлгә куючы вәкаләтләрен (устав капиталында катнашу өлешләре) гамәлгә ашыру тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар нигезендә; федераль законнарда каралган башка очраклардан тыш;”;

2) 28.1 маддәнең 3 өлешен түбәндәге эчтәлекле 2.1 пункты белән тулыландырырга:

“2.1) коррупциячел хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе доклады, анда аны башкаруның факттагы шартлары һәм бары тик аның ризалыгы белән генә һәм коррупциячел хокук бозу фактын тану шарты белән генә муниципаль хезмәткәрне язмача аңлатулары бәян ителә (ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат ителү рәвешендә түләтүдән тыш);”.

2. Әлеге Карарны түбәндәге адреслар буенча халыкка җиткерергә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Красновидово авылы, Совет урамы, 4 нче йорт;

- ТР, Кама Тамагы районы, Бортас авылы, Үзәк урам, 3 нче йорт;

-ТР, Кама Тамагы районы, Антоновка авылы, Колхоз урамы, 9а йорты,

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы Кама**
**Тамагы муниципаль районы**
**Красновидово авыл җирлеге”**
**муниципаль берәмлеге Башлыгы** **В. П. Оленин**